**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,

Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 19.12.2023** **№1914**

**Башкарма комитетның «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2023 елның 21 февралендәге 295 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм итү максатларында, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2023 елның 21 февралендәге 295 номерлы карарын түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча белән тулыландырырга:

«1.1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм иткән оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында күрсәтелгән бурычларны үтәүгә ярдәм итү йөкләмәләрен башкаруга бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалидка чыккан гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин